

2025 елнын 27 январында Рузаевка районы Шәриф Камал исемендәге Татар Пешлә урта мәктәбенә Кочкурово районы Сабаево урта мәктәбе укучылары Светлана Николай кызы Ибраһимова белән Лидия Кузминична Филатова укытучылары карамагында килгәннәр. Бу визит мәгариф оешмасы очен моһим вакыйга була, чонки ул тәжрибә уртаклашуга һәм уку йортлары арасында элемтәләрне ныгытуга ярдәм иткән. Айзатуллина Самира, Тайрова Амина белән Камила, Латышева Полина, Умряев Рамиль белән житәкчеләре очен мәктәп буйлап экскурсия оештырылган, анын кысаларында алар уку кабинетлары, спорт заллары һәм китапханә белән таныша алдылар.  Мәктәпнен горурлыгы булган Шәриф Камал музеена аерым игътибар бирелгән. Экскурсия барышында кунаклар якташыбыз, боек татар язучысы һәм жәмәгать эшлеклесе Шәриф Камалнын тормышы һәм ижаты турында остәмә материал белән танышалар: ул әдәбият һәм мәдәният тарихында сизелерлек эз калдырган.

Экскурсия кунакларны Татар Пешлә урта мәктәбе тарихы белән таныштыру гына тvгел, уку йортлары арасында хезмәттәшлек перспективалары турында да фикер алышырга момкинлек биргән. Тәжрибә ур-таклашу, уртак проектлар очен идеяләр һәм мәдәни инициативалар аралашунын vзәк темаларына әверелгән.

Шул ук конне укучылар Ислам мәдәни vзәгендә дә экскурсиядә булганнар.

Укучыларны Ислам мәдәни vзәге директоры Фатих Исхак улы Шафиев, директор урынбасары Шамиль хәзрәт Сабитов һәм Надия Низаметдин кызы Азисова каршы алган һәм мавыктыргыч сәяхәт музей, уку сыйныфы, конференц-зал, бай китапханәсе булган гыйбадәт залын кvрсәттеләр. Укучыларга татар тарихыннан кызыклы фактлар, ислам дине турында моһим мизгелләр, музей экспонатларынын килеп чыгышы турында да ишеттеләр. Шулай ук укучылар очен татлы сый әзерләнгән иде.